**Балалар бакчалары җитәкчеләре РМО беркетмәсе № 3**

**Үткәрү вакыты:** 31.01.2020.
**Үткәрү урыны:** Мари Суксу балалар бакчасы
**Катнашнашырга тиеш**: район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А., РМО җитәкчесе Аглямова М.В., балалар бакчалары мөдирләре, өлкән тәрбиячеләр.
**Катнашалар**: 42 бакча мөдире, 5 өлкән тәрбияче, РМО җитәкчесе Аглямова М.В., район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А.

**Тема**: Проектно-исследовательная деятельность детей, как вид деятельности, помогающий успешной реализации ФГОС ДО.

**Көн тәртибе:**
1. Ачык шөгыльләр һәм чаралар карау.
2. Мөдир Султангалина Ч.Ф. презентацияләнгән эш тәҗрибәсе белән уртаклашуы.
3. Балаларны тикшерү эшчәнлегенә йөрәтү буенча проект эшләр күргәзмәсе.
4. Төрлеләр.

**Утырыш барышы:**

1 нче көн тәртибе буенча практик эшчәнлек – шөгыльләр каралды.
"Путешествие в страну "Безопасное движение"" дигән темага 1 нче категорияле тәрбияче Арсланова А.И. катнаш төркем бн шөгыль күрсәтте. Тәрбияче шөгыльгә куелган бурычлары, максаты белән таныштырды, балалар контингенты турында әйтеп үтте.

- №7 өлкән тәрбиячесе Айгөл: тәрбияче ФГОСның бар өлкәләрендә алган, психологик настрой оештырган. Балалар күп белә, сөйләм телләре матур, грамматик яктан дөрес сөйлиләр. Эш даимилеге күренә, алдан эшләнгән.
- РМО җитәкчесе Аглямова М.: ФГОСка нигезләнеп шөгылен төзегән, балалар өчен кызыклы. Тәрбияче үзе бик эмоциональ, балаларга игътибарлы, активлыгын арттырып тора.
- Район мәгариф бүлеге методисты АхтямоваА.А.: Үрнәк шөгыль. Балалар даими хәрәкәттә.

2 нче шөгыль - театралҗлаштерелгән эшчәнлек, катнаш төрдәге балалар төркеме белән "Волк и семеро козлят на новый лад" әкиятен сәхнәләштерде.
Тәрбияче ачык чарага куелган бурычлары, максаты белән таныштырды.

- Киров балалар бакчасы мөдире Гайнанова Л.: "Төркемдә тырыш хезмәткәрләр эшләве тышкы яктан күренеп тора, бар җирдә дә матурлык, яктылык бөркелә, эстетик зәвык белән эшләнгән һәр әйбер. Тәрбияче тыныч, методиканы белә, чара өстендә күп эшләгән.
- № 7 балалар бакчасы мөдире Харисова А.М.: "Балалар бик эмоциональ, маскалары эстетикалы, гади".
- Пучы балалар бакчасы методисты Нургалиева Л.А.: "Әкиятне балалар теләп өйрәнгәннәр, ачык сөйләшәләр, активлар. Тәрбияче күп материал кулланып эшләде. Үз тәҗрибәсен электрон рәвештә таратса яхшы булыр иде, үзебезнең эшчәнлектә кулланыр идек".

2 нче көн тәртибе буенча мөдир Султангалина Ч.Ф. презентацияләнгән эш тәҗрибәсе белән уртаклашты кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

3 нче көн тәртибе буенча модир балаларны тикшерү эшчәнлегенә йөрәтү буенча проект эшләр күргәзмәсе белән таныштырды.

4 нче көн тәртибе буенча район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А. сөйләде. Яңалыклар белән таныштырды:

- Сайтларны тәртиптә тотарга, даими тикшерү булып тора. Ике теллелек сакланырга тиеш. Ст "О языках образования" ФЗ №126 от 24.07.1998 нигезләнеп эшләргә.
- Җиңүнең 75 еллыгына шигырьләр һәм рәсемнәр конкурслары булачак, балалар бакчалары эчендә оештыра башларга.
- Грантлар буенча: татнефть гранты чыкты, катнашырга.

- Куркынычсызлык чараларын буенча эшне дәвам итәбез.
- Белем бирү учрежденияләрендә туклануның сыйфатын контрольдә тоту буенча комиссия төзелде һәм алар даими урыннарда булачаклар (10 көнлек меню сервировка, технлогические карты,регламент о приемке продукции...).
- Республика күләм "Яшел ут" конкурсына катнашырга, альбомнарны 5 февральдә карау булачак.

**Карар:**

1. Проектлы тикшеренү эшчәнлеген өйрәнеп балалар белән эшчәнлектә кулланырга.
2. "Яшел ут" конкурсына катнашырга.

Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист : ___________ Ахтямова А.А.
РМО җитәкчесе: _________ Аглямова М.В.
Сәркатип: ____________ Шакурова Р. Д.